СОВЕТ ОМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“18” июля 2019 г. — № 3-49

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегендә 2016 елның 3 мартындагы 1-8 номерлы Омар авыл җирлеге Советы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

01.04.2019 елдагы № 48 – ФЗ санлы «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы Федераль законы,Татарстан Республикасының 13.07.2018 елның № 50-ТРЗ санлы «Татарстан Республикасының дәүләт гражданнары хезмәте һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы”ның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турындагы законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы 2016 елның 3 мартындагы 1-8 санлы Татарстан Республикасы Омар авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә ( 18.11.2016 №2-18, 15.05.2017 № 1-23,· 28.07.2017 № 3-24, 14.11.2017 № 2-28, 05.06.2018 № 2-34, 13.08.2018 №2-36, 20.11.2018 № 3-40, 14.12.2018 № 2-41, 21.03.2019 № 1-43 Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12.3 пунктның 6 пунктчасы. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслаучы документ»;

1.2. 25.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"25.8 өлешендә каралган конкурсны үткәрү турында мәгълүматта белем алганнан соң Гражданнар алмаштырылырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары төркемнәре; әлеге вазыйфаларга квалификация таләпләре; 25.8 өлеше нигезендә конкурска тапшырыла торган документлар исемлеге күрсәтелә; кабул итү урыны һәм вакыты; конкурсны үткәрү датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан укыту турында шартнамә төзүгә кандидатларны бәяләү һәм сайлап алу өчен файдаланыла торган конкурс процедуралары; язма биремнең темасы (конкурс комиссиясе

тарафыннан кулланыла торган конкурс процедураларының берсе язмача бирем булса), шулай ук башка мәгълүмат материаллары да булырга мөмкин.»;

1.3. Пункт 25.16. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясе дәгъвачыларны 25.11 өлешенең 1-6 пунктларында күрсәтелгән документлар нигезендә, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәяли. Җирле үзидарә органы карары буенча конкурс процедуралары индивидуаль әңгәмә, тест һәм (яки) язмача биремне күздә тота.».

2. . Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгы И.Г.Хәсәнҗановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.Г.Хәсәнҗанов /